Министерство образования и науки Республики Татарстан
Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования
«Дворец творчества детей и молодежи им. И.Х.Садыкова» Нижнекамского
муниципального района Республики Татарстан

ПРИНЯТА
на заседании педагогического совета
МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
Протокол № 1
от «31» августа 2022 г.

УТВЕРЖДАЮ
Директор МБУ ДО «ДТДиМ
им. И.Х. Садыкова» НМР РТ
_________Р.Н. Салихзянов
Приказ № 211
от «31» августа 2022 г.

# ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА «ФОЛЬКЛОР КРЯШЕН»

***Направленность:*** художественная
***Возраст учащихся:*** 9-17 лет
***Срок реализации:*** 5 лет (1008 часов)

***Составитель:***
Никитина Альбина Егоровна,
педагог дополнительного образования

Нижнекамск, 2022 год

## Укыту программасының информацион картасы

| | | |
|---|---|---|
| **1** | **Белем бирү оешмасы** | Өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең “И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” |
| **2** | **Программаның тулы исеме** | «Керәшен фольклоры” |
| **3** | **Программаның юнәлеше** | сәнгати |
| **4** | **Программаны төзүчеләр турында мәгълүмат** | |
| 4.1 | Ф.И.О. | Никитина Альбина Егоровна, өстәмә белем бирү педагогы |
| **5** | **Программа турында мәгълүмат:** | |
| 5.1 | гамәлгә ашыру вакыты | 5 ел |
| 5.2 | укучыларның яше | 9-17 яшькә кадәр |
| 5.3 | программага характеристика:<br>программаның тибы<br>- программаның төре<br>- программаны проектлау принцеплары<br>- укыту процессын<br>- оештыру эчтәлеге формасы | Үстерелешле өстәмә гомуми белем бирү программасы<br>модификацияле<br><br>дәрес |
| 5.4 | программаның максаты | Халкыбызның мирасын тирәнтен өйрәнү аша укучыларда үткәннәргә ихтирам тәрбияләү . |
| **6.** | **Белем бирү программасының формалары һәм алымнары** | Проблемалы-эзләү ысуллары, мөстәкыйль һәм гамәли эшләр, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр |
| **7.** | **Нәтиҗәлелекне мониторинглау формалары** | Әңгәмә, сораштыру, тестлар, биремнәр, кичәләр, төрле дәрәҗәдәге бәйгеләр |
| **8.** | **Программаның нәтиҗәлелеген тормышка ашыру** | |
| **9.** | **Программаны раслау һәм соңгы үзгәртү датасы** | |
| **10.** | **Рецензентлар** | Зиновьева Ф.М. - методист |

**ЭЧТӘЛЕК**

**1.** Аңлатма язуы........................................................................................4-10
2. Укыту планы
1нче ел ……………………………………………………….............................10-11
2нче ел …………………… ……………………………………....................14-15
3нче ел ……………………………………………………………...................................18
4нче ел……………………………………………………………........................21
5нче ел……………………………………………………………........................ 24
3. Программаның эчтәлеге
1 нче ел өчен ………………………………………………….....11-14
2 нче ел өчен …………………………………………………...............15-18
3 нче ел өчен...........................................................................................18-21
4 нче ел өчен ……………………………………………...........22-24
5 нче ел өчен ……………………………………………...........24-26
4. Программаның методик, дидактик һәм материаль-техник
яктан тәэмин ителеше ……………………..........................................................26-41
5. Кулланма әсбаплар……………………………….............................42
6.
Кушымта..............................................................................................................43

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

“Керәшен фольклор”ы *сәнгати юнәлештәге программа.*

Программа төп *норматив документлар* нигезендә төзелде:

- Бала хокуклары турында БМО конвенциясе;
- Программа «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ;
- Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе, 31.03.20022ел, №678-р;
- “Мәгариф” милли проекты кысаларында “Һәр баланың уңышы” федераль проекты, Россия Федерациясе Президенты каршындагы стратегик үсеш һәм милли проектлар советы президиумының 2018 елның 3 сентябрендәге 10 номерлы утырышы беркетмәсе белән расланган “Мәгариф” милли проекты;
- Россия Мәгариф министырлыгының “Балаларга өстәмә белем бирүнең төбәк системаларын үстерүнең максатчан моделен раслау турында” 2009 елның 3 сентябрендәге 467 номерлы боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында " 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы боерыгы;
- РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.08.2017ел, № 816 боерыгы белем бирү эшчәнлеген, электрон белем бирүне, дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә ашырганда куллану тәртибен раслау турында”;
- СП 2.4. 3648-20 “санитар – эпидемиологик таләпләр”РФ Баш дәүләт санитар табибының 28.09.2020 ел, №28 карары белән расланган” балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына” дигән темага ТР Министырлар кабинеты карары;
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» уставы.
- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «И.Х. Садыйков исемендәге Балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» балаларга өстәмә белем бирү программасын эшләү һәм раслау турында нигезләмә.

*Программаның актуальлеге.* Бүгенге заман баласы күбрәк үз вакытын телевизор алдында, интернет челтәрендә, планшет тотып үткәрергә ярата. Ә бу исә үз чиратында танып – белү активлыгын сүндерә, алга таба омтылу эшчәнлеген куып чыгара. Бала үз иптәшләре белән аз аралаша. Укучыларның күзгә – күз аралашуының бик түбән дәрәҗәдә булуы. Программа максатчан, тормышка сәләтле, иҗади һәм әхлакый яктан сәламәт шәхес тәрбияләү, аның рухиятен саклау һәм үстерү зарурлыгы булу шартларында төзелде

*Педагогик максатчанлык*

Ядкарьләргә кызыксыну уятып, борынгы бабаларыбызның үткән тормышын, буыннар бәйләнеше тарихын өйрәнеп, хәзерге заман тормышы белән чагыштырып аңлату, балалар күңеленең әхлакый, рухи үсешенә зур йогынты ясый. Әлеге программа музыкаль эшчәнлекнең барлык төрләре: кабул итү, башкару эшчәнлеге (җырлау, керәшен халкының музыка уен коралларын барлау), музыкаль иҗат һәм музыкаль-белем бирү эшчәнлеге белән чагылдырылган музыкаль тәрбия алымнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Фольклор иҗаты принципларында төзелә торган эшчәнлек баланың сәнгати-образлы, ассоциатив фикерләвен, фантазиясен үстерә, аның төрле иҗади күренешләрен активлаштырырга мөмкинлек бирә. Без үзебезнең мәдәни үткәнебезне, телебезне һәм музыкаль мирасыбызны онытмаска тиеш. Шуңа күрә фольклор бала җанының аерылгысыз өлеше, шәхес тудыручы башлангычы булырга тиеш. Шунлыктан да инде бу программа укучыларның көче җитәрлек чараларны тормышка ашыруда ярдәм итү, укучыларның дәрестән тыш вакытларын файдалы үткәрү, күмәк эшчәнлек, кызыксыну, иҗади сәләтләрне үстерү максатыннан чыгып төзелде.

*“Керәшен фольклоры” программасының башка программалардан үзгәлеге.*

Керәшеннәр телнең, йолаларның, бәйрәмнәрнең борынгы чорлардан ук килгән архаик формаларын саклаганнар. Керәшеннәрдә ел фасылларына, табигать күренешләренә, дини йолаларга нигезләнгән бәйрәмнәрнәр христиан календаре буенча үткәрелсә дә, аларда бары үзенчәлекле җырулар җырлана, үзенчәлекле такмаклар әйтелә. үзенчәлекле биюләр биелә.

Түбәндәге программа буенча белем алган балалар төрле яктан үсеш алалар, укчыларның гуманитар фәннәрдән белемнәре тирәнәя, күзәтергә, эзләнергә, фикерләргә, шул фикерне ачык итеп әйтә белергә, проект эшендә куллана белергә өйрәнәләр.

*Укучыларга дистанцион ярдәм күрсәтү формалары.*

Программаны тормышка ашырганда , мәгълүмати һәм компьютер технологияләре, шулай ук дистанцион укыту формалары актив кулланыла. Алынган белемнәрне ныгыту, гамәли күнекмәләрне камилләштерү өчен сайтлар белән дистанцион хезмәттәшлек алып барыла.

https://tatarica.org/ru/razdely/nauka/nauchnye-obshestva/obshestvo-izucheniya-tatarstana

https://urok.1sept.ru/статьи/649223/

https://yandex.ru/images/search?text

https://www.youtube.com/watch?v=B1H9sK7h_C4

https://uchi.ru/teachers/stats/main

**ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ**

Халкыбызның мирасын тирәнтен өйрәнү аша укучыларда үткәннәргә ихтирам тәрбияләү .

**БУРЫЧЛАР**

*Белем бирү :*

- балаларны керәшен халкының, шигъри һәм музыкаль иҗаты, традицион бәй-рәмнәре белән таныштыру;
- җырлау, музыка, хәрәкәт өлкәсендә башкару күнекмәләрен формалаштыру;
- балаларның туган як тарихы, халкы, мәдәнияте турында белемнәрен арттыру;
- балаларга берләшмәдә һөнәр юнәлеше бирү, аларда махсус белем һәм күнек-мәләр булдыру.

*Үстерү :*

- балаларда мөстәкыйльлек, инициатива һәм импровизация сәләтен үстерү;
- фольклор аша музыканы актив кабул итүне үстерү;
- музыкаль сәләтләрне үстерү.

*Тәрбия бирү :*

- керәшен  халкына, аның тарихына, сәнгатенә мәхәббәт уяту;
- балаларның социаль-әхлакый, психик сәламәтлеген формалаштыру;
- балаларның туган җиргә мәхәббәт, үз халкының гореф-гадәтләренә һәм хезмәт кешеләренә хөрмәт күрсәтү өчен шартлар тудыру;
- балаларда толерантлык тәрбияләү.

*Программаны тормышка ашыруда катнашучы балаларның яше.*

Берләшмәгә 9 яшьтән 17 яшькә кадәр барлык теләүче балалар кабул ителә. Уку төркемнәре түбәндәгечә формалаша: 1 ел уку - 15 кеше; 2 ел уку - 12 кеше; 3 - 5 ел уку - 10 кеше. Әлеге белем бирү программасы яшь аралыгын, укучылар үзенчәлеген исәпкә алып төзелгән. Бер төркемдә төрле яшьтәге балалар шөгыльләнә ала, әмма аларны уртак мәнфәгатьләр, омтылыш берләштерә.

*Программныңа күләме* 1008 *сәгать.* Программа 5 ел укытылуга язылган. Берләшмәдә укыту даими составта, төркемләп алып барыла. Беренче ел укыту сәгате – 144 сәгать; икенче, өченче, дүртенче, бишенче ел укыту - 216 сәгать тәшкил итә.

*Белем бирү процессын оештыру формалары*

Укыту барышында төрле дәресләр кулланыла: коллектив, индивидуаль, төркем, комбинация һәм практик дәресләр, лекцияләр, уеннар, бәйгеләр, бәйрәмнәр һәм башкалар. Ләкин ул ничек оештырылса да, коллектив эчендә шәхесара мөнәсәбәтләр тәрбияләүгә ярдәм итәрлек булырга тиеш.

Укытуның төп формасы-теория һәм практика сорауларын үз эченә алган комплекслы укыту. Балаларда нинди дә булса теманы үзләштерүдә кыенлыклар туганда, укытуны оештыру логикасына тиешле төзәтмәләр кертелә, өстәмәләр кертелә, әлеге теманы балаларда нәтиҗәлерәк кабул итү өчен иҗади юнәлешле ысуллар эшләнә. Укучыларның төрле бәйгеләрдә, массакүләм чараларда, экскурсияләрдә мәҗбүри катнашуы планлаштырыла. Дәресләрдә укучыларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләре исәпкә алына.

Укучының шәхесен, аның дөньяга карашын һәм иҗат сәләтләрен тәрбияләү һәр баланың яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләренә бәйле. Укучының гомуми һәм махсус үсешенә ирешү бурычы никадәр конкретрак итеп куелган саен, укыту формасы проблемасы да үзен ныграк сиздерә бара.

*Программаны үзләштерү вакыты*

Программа биш ел укутуга язылган. Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеген программа эчтәлеге һәм көтелгән нәтиҗәләр билгели.

*Дәрес режимы.* Дәреснең дәвамлылыгы СП 2.4. таләпләренә туры килә.3648-20 (2.10.2, 2.10.3, 3.6. 2п). Укучылар белән дәресләр үткәрелә: 1нче ел уку- атнага 2 тапкыр 2 академик сәгать белән, тәнәфес 10 минут. Икенче. өченче, дүртенче, бишенче ел укытылучы балалар атнага 2 көн 3 шәр сәгать белем алалар.

***Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре***

*Беренче ел укытуда көтелгән нәтиҗәләр:*

*Метапредмет күрсәткечләре:*

- тыңлый һәм диалогка керү;
- коллектив фикер алышуда катнашу;

- иҗади проблеманы аңлау;
- эшчәнлек нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

*Шәхси  күрсәткечләр*

- халык музыкасын кабул итү процессында үз эшләрен планлаштыра белү;
- баланың үзаңы үсүе, милләтне, ватанны ярата белүе, горурлык һәм гражданлык хисләре булу;
- үз халкың мәдәниятенә хөрмәт белән карау.

*Предмет күрсәткечләре*

*Беренче ел уку ахырына укучы*

*беләчәк*:

- эш урынын оештыру кагыйдәләрен;
- - дөрес сулыш алуны;
- - төп вокал-хор күнекмәләрен;

*булдырачак*:

- - җырны хәрәкәт һәм көй белән бергә алып бара;
- *халык алдында сөйләү күнекмәләренә ия;*

*Икенче ел укытуда көтелгән нәтиҗәләр:*

*Метапредмет күрсәткечләре.*

- халык алдында сөйләү күнекмәләренә ия;
- иҗади бурычны аңлау;
- план буенча эш итү һәм үз эшчәнлегеңне планлаштыру;
- бәяләүләрне һәм билгеләрне  кабул итү;
- башка укучыларның нәтиҗәләрен гадел бәяләү;
- үз-үзеңне танып белү һәм дөньяны танып белү ысулы буларак иҗади эшчәнлек белән кызыксыну;

*Шәхси  күрсәткечләр*

- ихтыяр көче, максатка ирешүдә ныклык, авырлыкларны җиңәргә әзер булу:
- җаваплылык, башкаручанлык, хезмәт сөючәнлек, пөхтәлек күрсәтү һ. б.;
- гомуми иҗади эшкә җәлеп итү аша коллектив үзара бәйләнешнең ихтыяҗын һәм күнекмәләрен күрсәтү;

*Предмет күрсәткечләре*

*Икенче ел уку ахырына укучы*

*беләчәк*:

- сәхнәдә үз-үзен тота белә;
- дөрес сулыш ала;
- өйрәнелә торган материалны анализлый белә;
- тарихи момент һәм фактларны аңлата һәм исбатлый белә;

*булдырачак*:

- чылбырлы сулышка ия;
- йомшак,  җиңел җырлый;
- мелодик яктан катлаулы булмаган җырларны башкара.

*Өченче ел укытуда көтелгән нәтиҗәләр:*

*Метапредмет күрсәткечләре.*

- вокал партияләрен мөстәкыйль өйрәнә белә;
- тыңлый һәм диалогка керә;
- коллектив фикер алышуда катнаша белә;
- халык музыкасын кабул итү процессында үз эшләрен планлаштыра белә;

*Шәхси күрсәткечләр*

- дөнья мәдәниятен төрле милли формаларда аңлый һәм хөрмәт итә;
- җаваплылык, башкаручанлык, хезмәт сөючәнлек, пөхтәлек күрсәтү һ. б.;
- база кыйммәтләрен бәяли һәм кабул итә: «Ватан», «халык», «яхшылык», «милләт» һ. б.;

*Предмет күрсәткечләре*

*Өченче ел уку ахырына укучы*

*беләчәк*:

- өйрәнелә торган материалны анализлый;
- сәхнәдә чыгыш ясап үзенең сәләтен күрсәтә белә,;
- тарихи момент һәм фактларны аңлата һәм исбатлый белә;
- игенчелек календаренең төп даталары, алар белән бәйле бәйрәмнәр һәм уеннар тарихын

*булдырачак*:

- әсәр характерында сулыш ала;
- музыкаль әсәрләрне фольклор коллективы составында дөрес башкара ала, әсәрләрне тыңлый, аларның жанрын һәм характерын билгели.

*Дүртенче ел укытуда көтелгән нәтиҗәләр:*

*Метапредмет күрсәткечләре.*

- музыкаль-бию импровизацияләрен булдыра;
- музыкаль-иҗади эшчәнлеген бәяли;
- халык алдында сөйләү күнекмәләренә ия.

*Шәхси күрсәткечләр*

- иҗади шәхес сыйфатлары формалаштырыла;
- уңыш/уңышсызлык сәбәпләрен адекват хөкем итү сәләтенә ия;
- олылар һәм яшьтәшләр белән аралаша белә.

*Предмет күрсәткечләре*

*Дүртенче ел уку ахырына укучы*

*беләчәк*:

- иҗади хезмәтне оештыра,
- игенчелек календаренең төп даталары, алар белән бәйле бәйрәмнәр һәм уеннар тарихын белә;
- керәшен халкының биюле уеннарын белә.

*булдырачак*:

- сәләте буенча табигать бәйрәмнәре һәм йолалары буенча этюдлар күрсәтә;
- кичә - концертларда чыгыш ясый;
- җырлауны бию хәрәкәтләре белән берләштерә.

*Бишенче ел укытуда көтелгән нәтиҗәләр:*

*Метапредмет күрсәткечләре.*

- халык алдында сөйләү күнекмәләренә ия;
- вокал партияләрен мөстәкыйль өйрәнә;
- тыңлый һәм диалогка керә, коллектив фикер алышуда катнаша белә;

*Шәхси күрсәткечләр*

- кешеләргә ышанычлы, игелеклелекле һәм игътибарлы;

-илебезнең сәнгать культурасы белән танышу нигезендә эстетик хисләр һәм матурлык хисе формалашкан;

- олылар һәм яшьтәшләре белән аралаша белә.

*Предмет күрсәткечләре*

*Бишенче ел уку ахырына укучы*

*беләчәк*:

- сәхнәдә чыгыш ясап үзенең сәләтен күрсәтә;
- бию рәсемнәрен аңлап мезанценалар төзи;
- керәшен халкына кагылышлы тарихи момент һәм фактларны аңлата һәм исбатлый белә;
- җырлы – биюле уеннар, борынгы авыл җыруларын, өс киемнәренең үзенчәлекләрен белә;
- - сәләте буенча иҗади хезмәтне оештыра белә.

*булдырачак*:

- чылбырлы сулышка ия;
- сәләте буенча табигать бәйрәмнәре һәм йолалары буенча кечкенә сценарий яза белә;
- шәһәрнең мөһим даталарына багышланган тематик бәйрәмнәрдә катнаша;
- халык җыры репертуарын башкару буенча төрле алымнар белән гамәли күнекмәләргә, соло һәм ансамбльдә фольклор импровизациясе күнекмәләренә ия;
- халык җырын сәхнәдә чагылдыру, халык йолалары һәм фольклор традицияләрен, шул исәптән театральләштерелгән фольклор композицияләрен башкару күнекмәләренә ия.

*Программаны тормышка ашыруга йомгак ясау формалары*

Укыту процессының нәтиҗәлелеген төрле аттестация формалары күрсәтә:

а) кереш контроль - сораштыру, мини-тест;

б) агымдагы контроль – биремнәр;

в) арадаш контроль – Балалар һәм яшьләр иҗаты сараенда уздырылучы кичәләрдә катнашу; район, республика күләмендәге бәйгеләрдә катнашу һәм нәтиҗәлелеген анализлау;

г) йомгаклау контроле - биш еллык уку курсы тәмамланганнан соң шәһәркүләм кичәдә катнашу формасында үткәрелә. Йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән чыгарылыш укучыларына "Керәшен фольклоры" өстәмә гомуми белем бирү программасын үзләштерү турында таныклык бирелә.

## 1 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № | Тема | Сәг.саны. | Теория | Практика | Аттестация формалары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. | 2 | 2 | - | кереш дәрес, сорашу |
| 2 | Нәсел агачы-шәҗәрә. | 8 | 4 | 4 | мөстәкыйль эш |
| 3 | Спорт-сәламәтлек нигезе. | 10 | 4 | 6 | эшлекле уен |
| 4 | Мин яратам сине , Татарстан! | 12 | 8 | 4 | карточкалар белән эш |
| 5 | Туган ягым-горурлыгым! | 12 | 4 | 8 | проект |
| 6 | Батырларга мәңгелек дан! | 18 | 4 | 14 | проект |
| 7 | Туган якның данлы шәхесләре. | 20 | 14 | 6 | иҗади эш |
| 8 | Нинди гүзәл минем туган ягым! | 10 | 4 | 6 | бирем |
| 9 | Кыңгыраулы мәктәп еллары | 14 | 4 | 10 | аралашу |
| 10 | Үткәнен белмәгәннең –киләчәге юк! | 12 | 2 | 10 | иҗади эш |
| 11 | Исемнәр ни сөйли? | 6 | 2 | 4 | иҗади бәйге |
| 12 | Керәшен халкымның данлы йолалары | 8 | 2 | 4 | эшлекле уен |
| 13 | Музей эше нигезләре | 10 | 4 | 6 | аралашу |
| 14 | Йомгаклау дәресе | 2 | - | 2 | тест |
| | Барлык сәгать: | 144 | 58 | 86 | |

## 1 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема: кереш дәрес**

Максат: Балаларны барлау, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен искә төшерү, уку елы планы, бүлек планына кертелгән кичә, бәйгеләр белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә. Туган як тарихын өйрәнү электив курсның максаты һәм бурычлары. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә, сорашу.

*Күрсәтмә материал* : Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (1-4 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.

*Җиһазлау*: компьютер, китаплар.

**2 тема: нәсел агачы- шәҗәрә**

Максат: шәҗәрәнең тирән мәгънәсенә төшендерү,буыннар тарихы, тарихи ядкарьләр белән кызыксыну уяту; иҗади сәләтләрен үстерү; әхлаклылык тәрбиясе бирү.

“Нәсел агачы- шәҗәрә”. Нәрсә ул шәҗәрә? Аны төзү тәртибе.

Шәҗәрәләрне өйрәнү тарихы. Шәҗәрә һәм аны төрле формада ясау.

Шәҗәрә белән танышу.

Минем нәсел шәҗәрәм. Практик эш.

*Күрсәтмә материал:* борынгы шәҗәрәләр

*Җиһазлау*: китаплар, шәҗәрәләр.

**3 тема: спорт –сәламәтлек нигезе.**

Максат: туган ягыбыз табигатенең сәламәтлек өчен файдасы никадәр зур булуын аңлату, спорт турында фикерләү сәләтләрен үстерү, спорт сөючеләре белән горурлану хисләре , сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү.

Иртәнге гимнастик күнегүләр комплексын өйрәнү, “Күңелле стартлар”, табигатькә экскурсия, рәсемнәр конкурсы: “Матур киләчәк.”

*Җиһазлау*: спорт инвентарьләре.

**4 тема: мин яратам сине , Татарстан!**

Максат: үз Ватаныбыз тарихы, мәдәнияте, горур халкы, аның гореф-гадәт, йолалары белән таныштыру, горурлык хисләре тәрбияләү.

Керәшен халкының милли йолалары, Татарстанның куренекле шәхесләре белән танышу, “Туган ягым”- Татарстан гимны (гимнны өйрәнү), Татарстан дәүләт символлары (пр.эш) Керәшеннәрнең Дәүләт фольклор ансамбле “Бермәнчек”, фольклор ансамбле “Сәләм.” Татарстан Республикасының фольклор Дәүләт ансамбле ”Риваять”. Иң кызыклы һәм истә калган тапшырулар хакында сөйләшү. Сәнгать үзенчәлекләре турында сөйләү.

*Күрсәтмә материал:* Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт символлары; дөньяның сәяси картасы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы карталары.

*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма.

**5тема: туган ягым –горурлыгым.**

Максат: үз шәһәребез тарихы, мәдәнияте белән тирәннән танышу, бөек шәхесләре белән таныштыру, патриотик тәрбия бирү.

Үз шәһәребез тарихы, мәдәнияте белән тирәннән танышу, бөек шәхесләре белән таныштыру “Туган ягым табигате” рәсемнәр, иншалар конкурсы, архитектура истәлекләре, Түбән Кама буйлап экскурсия
*Күрсәтмә материал:* “Күренекле кешеләр” альбомы
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, альбом.

**6 тема: батырларга мәңгелек дан!**
Максат: туган ягыбызның батыр ул-кызлары, сугыш һәм хезмәт ветераннары турында сөйләү, патриотик тәрбия бирү.
атырлык нәрсә ул? Батырлык эшләр идем.(әңгәмә-дәрес), “Алар Җиңү китерде!”- шәһәребезнең сугыш ветераннары турында, “Туган якны өйрәнү” музееның “Сугышчан дан” бүлегенә экскурсия.
Сугыш чоры елъязмалары, альбомнары, истәлекләр белән танышу, Бөек Ватан сугышында керәшен халык геройләре турында сөйләү, “Йолдызлы сәгать”үткәрү. Ветераннарның өйләренә бару, хәлләрен белү, ярдәм итү.
*Күрсәтмә материал:* Хәтер.Татарстан Республикасы, Казан, Хәтер китабы нәшр.,1996.
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма.
**7 тема: туган якның данлы шәхесләре.**
Максат**:** туган ягыбызның күренекле шәхесләре белән таныштыру, очрашулар үткәрү, балаларның иҗади һәм фикерләү сәләтләрен, сөйләм телләрен үстерү, шәхесләр белән горурлану хисләре тәрбияләү.
Кемнәр алар данлы шәхесләр? Шәһәребездән чыккан бөек затлар – әңгәмә, шәһәребез рәссамы – Әхсән Фәтхетдинов музеена экскурсия, Разил Вәлиев, Мария Логинова, Анастасия Усачёва, Никифор Тукмачёв иҗаты. Шигырьләр уку, әңгәмә оештыру.
*Күрсәтмә материал:* данлы шәхесләрнең портретлары, китаплары
*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма, “Түбән Камам” аудиоязмасы
**8 тема: нинди гүзәл минем туган ягым.**
Максат: балаларның табигать, экология турында белемнәрен арттыру, табигатькә сакчыл караш, туган ягыбызның матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү.
“Нинди гүзәл минем туган ягым!”- Түбән Кама табигате, халкы, чишмә-таулары тарихы белән танышу, шәһәрем урамнары буйлап экскурсия, рәсемнәр ясау, уен – викторина, “Туган җирем минем”- тупланган материаллар, фотолар белән альбом төзү.(Практик эш)
*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма, китаплар, рәсемнәр
**9 тема: кыңгыраулы мәктәп еллары.**
Максат: мәктәп тарихы, мәдрәсә тарихлары белән тирәннән танышу, анда укып чыккан гыйльми кешеләр тормышы белән танышу, мәктәпнең бүгенге көне, укытучылар турында сөйләшү, белемгә аңлы караш тәрбияләү.
Беренче мәктәп тарихы белән танышу, укытучылар турында сөйләшү, “Сез иң гүзәл кеше икәнсез”- мәктәбем укытучылары –түгәрәк өстәл.
”Яраткан фәнем “-эшлекле уен, беренче мәктәп музеена экскурсия.
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, китаплар, рәсемнәр.
**10 тема: үткәнен белмәгәннең-киләчәге юк.**

Максат: укучыларда буыннар бәйләнеше, тарихи ядкарьләргә кызыксыну уяту, авылыбыз тарихлары белән танышу, музейга экскурсия ясау, үткәннәргә ихтирамлылык хисләре тәрбияләү.
Түбән Кама шәһәре тарихы, килеп чыгышы, тарихи истәлекле урыннарга экскурсия, архитектура истәлекләре белән танышу,фотоларга төшерү, презентация ясау, “шәһәрем элек һәм хәзер” рәсем конкурсы.

*Җиһазлау*: компъютер, магнитофон, видеоязма, китаплар, рәсемнәр

**11 тема: исемнәр ни сөйли?**

Максат: исемнәр аталышының мәгънәләренә төшендерү, фикерләү сәләтләрен үстерү, әхлак тәрбиясе бирү.
“Исемең матур кемнәр куйган?”- исемнәр, аларның мәгънәләре турында сөйләшү? Шәһәребез урамы исемнәренең аталышы, аларның мәгънәсе, шәһәребездәге промышленность предприятиеләре,сәүдә нокталары, мәгариф,спорт, сәнгать учаклары исемнәренең аталышы, мәгънәсе.

*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, китаплар, рәсемнәр

**12 тема: Керәшен халкымның данлы йолалары**

Максат: керәшен халкының гореф-гадәтләре, дини бәйрәмнәр, йолалары белән таныштыру, мәдәни чаралары турында сөйләп аңлату, милләтебез белән горурлану хисләре тәрбияләү. Кышкы, язгы, җәйге, көзге бәйрәмнәр. Халык календаре, аларның килеп чыгу тарихы..
Шәһәр китапханәсенә сәяхәт, борынгы уеннарны искә төшерү: «Ша», «Балдак салыш», «Терсәк күрсәтү», «Шома басу», “Торна” уеннарын уйнату.
*Күрсәтмә материал:* Татар халык ижаты. Йола һәм уен җырлары. К.1980г (Татарское народное творчество. Обрядовые и игровые песни).

*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон.

**13 тема: музей эше нигезләре.**

Максат: музей эшчәнлеге, мөһим документлар, экспонатларны саклау тәртипләре белән таныштыру, экскурсоводлар ролен башкарырга өйрәтү.
Музейлар, аларның төрләре, ”Туган якны өйрәнү” музее эше нигезе нидән гыйбарәт? Музей бүлекләре. Аларның төп үзенчәлеге, эчтәлеге, әһәмияте, музей документлары, музейның иң кыйммәтле экспонатлары, иң мөһим кәгазьләр белән танышу, мәктәпнең ”Туган якны өйрәнү” музеена экскурсия ясау, документлар, мөһим кәгазьләр белән танышу, музейдагы иң кыйммәтле экспонатлар, аларны саклау тәртибе, музейда бүлеп бирелгән бүлекләр буенча экскурсия оештырып карау : ”Без яшь экскурсоводлар”.
*Күрсәтмә материал:* Ю.Г. Мөхәмәтшин.Татары –кряшены. Историко-этнографическое исследование материальной культуры. Середина XIX - начало XX в. Издательство «Наука», Москва, 1977.

**14 тема: йомгаклау дәресе.**

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.
Еллык эшебезгә нәтиҗә ясау. Алдагы уку елына планнар. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау. Тест сорауларына җавап бирү.

## 2 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № | Тема | Барлык сәгать | Теория | Практика | **Аттестация формалары** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Юл йөрү буенча кагыйдәләре буенча әңгәмә. | 3 | 3 | - | кереш контроль – мини тест |
| 2 | Минем гаиләм | 15 | 3 | 12 | мөстәкыйль эш |
| 3 | Безнең мәктәп | 15 | 3 | 12 | эшлекле уен |
| 4 | Туган ягым табигате | 24 | 3 | 21 | карточкалар белән эш |
| 5 | Туган ягым җәнлекләре | 12 | 6 | 6 | карточкалар белән эш |
| 6 | Микрорайонның күренекле кешеләре | 30 | 12 | 12 | аралашу |
| 7 | Шәһәрем тарихы | 33 | 9 | 24 | рәсем бәйгесе |
| 8 | Тарих эзләре буйлап | 27 | 6 | 21 | тест |
| 9 | Татарстан минем республикам | 24 | 12 | 12 | аралашу |
| 10 | Спорт-сәламәтлек нигезе | 18 | 6 | 12 | эшлекле уен |
| 11 | Бөек Җиңү | 12 | 3 | 9 | реферат язу |
| 12 | Йомгаклау | 3 | - | 3 | иҗади эш |
| | Барлык сәгать: | 216 | 66 | 150 | |

## 2 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема: кереш дәрес**

Максат: Балаларны барлау, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен искә төшерү, уку елы планы, бүлек планына кертелгән кичә, бәйгеләр белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә. Юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

*Күрсәтмә материал* : Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (1-4 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.

*Җиһазлау*: компьютер, китаплар.

**2 тема: минем гаиләм**

Максат:гаиләдә татулык нидән гыйбәрәт, әти- әниләрнең хезмәте . көн-күрешләре белән танышу; иҗади сәләтләрен үстерү; әхлаклылык тәрбиясе бирү.
*Күрсәтмә материал* : портретлар, гаилә фотолары
*Җиһазлау*: китаплар, пластинкалар

**3 тема: безнең мәктәп**

Максат: мәктәп тарихы белән тирәннән танышу, мәктәпнең бүгенге көне, без нәрсә белән ярдәм итә алабыз,мәктәп китапханәсе белән танышу, кабинетларга экскурсия оештыру;белемгә аңлы караш тәрбияләү.
*Күрсәтмә материал: стендлар, музей альбомнары.*
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, китаплар, рәсемнәр

**4 тема: туган ягым табигате**

Максат: балаларның табигать, экология турында белемнәрен арттыру, табигатькә сакчыл караш, туган ягыбызның матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү. Урам буйлап экскурсия,
рәсемнәр ясау, уен – викторина, тупланган материаллар, фотолар белән альбом төзү.(Практик эш)
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, китаплар, фото рәсемнәр.

**5 тема: туган ягым җәнлекләре**

Максат: балаларның җәнлекләр, табигать, экология турында белемнәрен арттыру, табигатькә сакчыл караш, туган ягыбызның матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү, Кызыл китап белән, җәнлекләрең кешеләргә нинди ярдәмнәре тиюе белән таныштыру.
*Күрсәтмә материал:* кызыл китап белән таныштыру, И.И.Шишкин картиналарын карау.
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма.

**6 тема: микрорайонның күренекле кешеләре**

Максат: укучыларда буыннар бәйләнеше, тарихи ядкарьләргә кызыксыну уяту, үз микрорайонның күренекле кешеләре белән танышу, музейга экскурсия ясау, үткәннәргә ихтирамлылык хисләре тәрбияләү.
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, китаплар, рәсемнәр.

**7 тема: шәһәрем тарихы**

Максат: үз микрорайонның ничек барлыкка килүе белән танышу, музейга экскурсия ясау, үткәннәргә ихтирамлылык хисләре тәрбияләү.
Урам буйлап экскурсия, архитектура истәлекләре белән танышу, фотоларга төшерү, презентация ясау, “шәһәрем элек һәм хәзер” рәсем конкурсы.
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, китаплар, рәсемнәр.

**8 тема: тарих эзләре буйлап**

Максат: Түбән Кама шәһәренең ничек барлыкка килүе белән танышу, музейга экскурсия ясау, үткәннәргә ихтирамлылык хисләре тәрбияләү.

Түбән Кама шәһәре тарихы, керәшен авыллары. “Чабья”, “Актүбә” урыннары буйлап экскурсия, архитектура истәлекләре белән танышу, фотоларга төшерү, презентация ясау.

*Күрсәтмә материал:* Кашипов М.Н. Җырлыйк та, бииктә. Поём и танцуем. Казань, 1988,

*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, китаплар, рәсемнәр.

**9 тема: Татарстан минем республикам**

Максат: үз Ватаныбыз тарихы, мәдәнияте, керәшен халкы, аның гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру, горурлык хисләре тәрбияләү; Татарстанның күренекле шәхесләре белән танышу, горурлык хисләре тәрбияләү.

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар.

*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма.

**10 тема: спорт-сәламәтлек нигезе**

Максат: шәһәребезнең спорт һәм мәдәни объектлары белән танышу, экскурсияләргә бару, туган ягыбызның күренекле шәхесләре белән таныштыру, очрашулар үткәрү, балаларның иҗади һәм фикерләү сәләтләрен, сөйләм телләрен үстерү, шәхесләр белән горурлану хисләре тәрбияләү.

*Күрсәтмә материал:* данлы шәхесләрнең портретлары, китаплары.

*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма, “Түбән Камам” аудиоязмасы.

**11 тема: Бөек Җиңү**

Максат**:** туган ягыбызның батыр ул-кызлары, сугыш һәм хезмәт ветераннары турында сөйләү, очрашулар үткәрү, патриотик тәрбия бирү; ветераннарның өйләренә бару, хәлләрен белү, ярдәм итү, әңгәмә кору.

*Күрсәтмә материал:* музей материаллары, Татарстан Республикасы, Казан, Хәтер китабы.

*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязмалар.

**12 тема: йомгаклау дәресе.**

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.

Еллык эшебезгә нәтиҗә ясау. Фикерләр алышу. Алдагы уку елына планнар. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау. Бер темага реферат белән чыгыш ясау.

## 3 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № | Тема | Барлык сәгать | Теория | Практика | **Аттестация формалары** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Юл йөрү буенча кагыйдәләре буенча әңгәмә. | 3 | 3 | - | тест |
| 2 | Татарстан – минем Республикам | 9 | 3 | 6 | мөстәкыйль эш |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Татарстанның күренекле мәдәният хезмәткәрләре | 15 | 3 | 12 | аралашу |
| 4 | Керәшен гаиләсе | 21 | 3 | 18 | аралашу |
| 5 | Керәшеннәрнең көнкүреш тәрбиясе | 24 | 3 | 21 | кече тест |
| 6 | Керәшен халкының авыз-тел иҗаты | 60 | 12 | 48 | үзлектән эш, тыңлау |
| 7 | Табигать бәйрәмнәре һәм йолалар | 69 | 9 | 60 | эшлекле уен |
| 8 | Табигать – безнең йортыбыз | 6 | 3 | 3 | сорашу |
| 9 | Татарстанның каһарманнары | 6 | 3 | 3 | мөстәкыйль эш |
| 10 | Йомгаклау | 3 | - | 3 | иҗади эш |
| | Барлык сәгать: | 216 | 70 | 174 | |

## 3 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема: кереш дәрес**
Максат: Балаларны барлау, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен искә төшерү, уку елы планы, бүлек планына кертелгән кичә, бәйгеләр белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.
*Күрсәтмә материал* : Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (1-4 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.
*Җиһазлау*: компьютер, китаплар.

**2 тема: Татарстан минем республикам**
Максат**:** үз Ватаныбыз тарихы, мәдәнияте, керәшен горур халкы, аның гореф-гадәт, йолалары белән таныштыру,горурлык хисләре тәрбияләү; Татарстанның күренекле шәхесләре белән танышу, горурлык хисләре тәрбияләү
*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар
*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма
**3 тема: Татарстанның күренекле мәдәният хезмәткәрләре**

Максат: Керәшен  халкының сәхнә осталарын танып-белүенең мөһимлеге, Татарстанның күренекле шәхесләре, рәссәмнәр һәм  композиторлар, милли үзенчәлек һәм сәнгать осталары,  фольклор сәнгатенә уңай караш, горурлык хисләре тәрбияләү, халык шагыйрьләре, артистларының сәхнә ижаты, театрга хөрмәт һәм сөю уяту.
*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.
*Җиһазлау*:  компьютер, магнитофон, видеоязма.

**4 тема: керәшен гаиләсе**

Максат: Өлкәннәр һәм балалар арасында мөнәсәбәттең нинди булырга тиешлеген аңлату, яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү, гаиләдә татулык нидән гыйбәрәт, әти- әниләрнең хезмәте,  көн-күрешләрен аңлату. Нәселдәге хөрмәтле затларны ихтирам итәргә, белергә өйрәтү.
*Күрсәтмә материал* : портретлар, гаилә фотолары.
*Җиһазлау*:   китаплар, пластинкалар.

**5 тема: керәшеннәрнең көнкүреш тәрбиясе**

Максат: Керәшен  халкының киемнәренең төрлелегенең  әһәмиятен аңлату. Хатын-кызлар, ир-егетләр  киемендәге үзенчәлекләр. Халыкта һәр бизәкнең оло мәгнәсе  булуын аңлату. Керәшен эчемлекләренә, ашларына мәхәббәт тәрбияләү, саулыкка файдасын  аңлату.  Борынгыдан килгән шифалы эчемлекләр турында аңлату, ашларга мәхәббәт тәрбияләү.
*Күрсәтмә материал* : Тукыма үрнәкләре, күргәзмә оештыру
*Җиһазлау*:   китаплар, борынгы табак-савытлар.

**6 тема: керәшен халкының авыз-тел иҗаты**

Максат: Балалар әдәбиятенә мөхәббәт тәрбияләү, балалар фольклоры, язучылары белән танышу. Бәйрәмнәрне  белү, саклап  калуга төшендерү, бәйрәмнәрне белү. Гөреф  – гадәтләр уеннарнын саклап калу, мөхәббәт тәрбияләү, йолаларны белү. Сәнгатебезгә мәхәббәт тәрбияләү, җыр сәнгате белән таныштыру. Бию осталыгына өйрәтү, ишетү сәләтен үстерү.
*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.
*Җиһазлау*:  компьютер, магнитофон, видеоязма.

**7 тема: табигать бәйрәмнәре һәм йолалары**

Максат: Ел фасылы белән бәйле сынамышларның тормыш көнкүрештә кирәклеге турында төшендерү. Гасырдардан килгән уеннар, туй  йолалары, бүген дә әһәмиятле булуын төшендерү. Музыкаль бизәлеш  өстендә  эшләү, ишетү, сәләтне үстерү. Табигатьтә  кыш аенда “Раштуа”, “Нардуган”, “Май чабу”, яз аенда “Бермянчек”, “Оло Кон”,“Тручын”, җәй аенда “Ивану”, “Питрау”, “Элжен”, көз аенда “Пыкрау”, “Микайле”,“Микула “  бәйрәмнәренең килеп чыгышы турында аңлату  .
*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.
*Җиһазлау*:  компьютер, магнитофон, видеоязма.

**8 тема: табигать – безнең йортыбыз**

Максат: Табигатьне саклау, кеше табигатьнең бер өлеше икәнлеген аңлату, мөхәббәт тәрбияләү, үз илеңнең, туып үскән җиреңнең кирәклеген аңлату.
Халык календары.
Үз күзәтүләреңнән халык календарен төзү ,аңлау, өйрәнү.
*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма.

**9 тема: Татарстанның каһарманнары**

Максат**:** 1941-1945 ел Бөек Ватан сугышында керәшен халык геройларе, ил азатлыгы өчен көрәшкән каһарманнарны олылау хисләре тәрбияләү, туган як азатлыгын яклау һәм саклау, һәр кеше өчен мөһим булуын төшендерү туган ягыбызның батыр ул-кызлары, сугыш һәм хезмәт ветераннары турында сөйләү, очрашулар үткәрү, патриотик тәрбия бирү; ветераннарның өйләренә бару, хәлләрен белү, ярдәм итү,әңгәмә кору.
*Күрсәтмә материал:* музей материаллары, Татарстан Республикасы, Казан, Хәтер китабы
*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязмалар.

**10: йомгаклау дәресе.**

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.
Еллык эшебезгә нәтиҗә ясау. Нинди уңышларга ирештек. Фикерләр алышу. Алдагы елларга планнар. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау. Иҗади эш эшләү.

## 4 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № | Тема | Барлык сәгать | Теория | Практика | **Аттестация формалары** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Юл йөрү буенча кагыйдәләре буенча әңгәмә. | 3 | 3 | - | кереш тест |
| 2 | Табигәть байлыклары | 15 | 3 | 12 | мөстәкыйль эш |
| 3 | Халкыбызның гореф- - гадәтләре. | 18 | 3 | 15 | аралашу |
| 4 | Халык сагышы – биюле уеннарда | 33 | 3 | 30 | аралашу |
| 5 | Халык язмышы – җыруда | 42 | 6 | 36 | иҗади эш |
| 6 | Керәшен халык биюләре | 27 | 3 | 24 | үзлектән һәм иҗади эш |
| 7 | Табигатьнең яз, кыш,җәй, көз | 60 | 12 | 48 | эшлекле уен |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бәйрәмнәре һәм йолалары | | | | |
| 8 | Инструмент-кораллар. | 15 | 6 | 9 | үзлектән эш |
| 9 | Йомгаклау | 3 | - | 3 | иҗади эш |
| | Барлык сәгать: | 216 | 39 | 177 | |

## 4 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема: кереш дәрес**
Максат: Балаларны барлау, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен искә төшерү, уку елы планы, бүлек планына кертелгән кичә, бәйгеләр белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.
*Күрсәтмә материал* : Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (1-4 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.
*Җиһазлау*: компьютер, китаплар.
**2 тема: табигать байлыклары**
Максат: Казылма байлыкларны танып белү, саклау, өйрәнү, күргәзмә оештыру. Табигатьне саклау, кеше табигатьнең бер өлеше икәнлеген аңлату. Табигатькә экскурсия. Изге чишмәләрне саклап калу, өйрәнү. Туган ягыбызның матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү. Урам буйлап экскурсия, рәсемнәр ясау, уен – викторина, тупланган материаллар, фотолар белән альбом төзү. (Практик эш)
*Күрсәтмә материал* : күргәзмә оештыру.
*Җиһазлау*: компьютер, китаплар.
**3 тема: халкыбызның гореф- -гадәтләре.**
Максат: Халкыбызның гореф- -гадәтләре. Белән таныштыру.“Покрау” бәйрәменең гореф-гадәтләре, көзне озату – кышны каршылау. Яшь әтәч сую йоласы, пешерену турында сөйләү, өйрәнү. Халыкларның тормыш яшәү рәүшендәге үзенчәлекләре һәм аермалыкларын күрә белү һәм аңлау.
*Күрсәтмә материал:* китаплар, фотоальбом.
*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма.
**4 тема: халык сагышы – биюле уеннарда**
Максат: балаларга гасырдардан килгән җырулар, жырлы – биюле уеннар өйрәтү, башкару осталыгын үстерү, мәхәббәт тәрбияләү, бүген дә әһәмиятле булуын төшендерү. Сүзләрне дөрес өйрәнү, сулышны дөрес алу**.** Җырлы – биюле уеннар: “Алсу алма, кура җиләк, чияләр”., “Терсәк күрсәтү», «Җебегән», «Торналар» уенын өйрәтү, рәсемнәр ясау, уеннардагы такмакларны өйрәнү.
*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма.

**5 тема: халык язмышы – җыруда**

Максат: Түбән Кама Чабья авылының "Урам кое" җыруын өйрәтү, борынгы авыл җырулары башкару осталыгын үстерү, мәхәббәт тәрбияләү, җыр сәнгате белән таныштыру. Шаян, рифмалы такмаклар өйрәнү, кашыклар, инструментлар кушу. Кунаклар каршы алганда җырланыла торган җырулар. Никрут көе- солдат озатканда җырлана торган җырлар, мөнәҗәтнең яшәү хакында философик фикерләү икәнен төшендерү,тыңлау, өйрәтү.

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: магнитофон, видеоязма.

**6 тема: керәшен халык биюләре**

Максат: Керәшен мәдәниятынең төрле жанрларын күрсәтү, фольклор сәнгатенә уңай караш, бию осталыгына өйрәтү, сәләтне үстерү, тәрбияләү. "Менделеевск ягы Иске Гришкино аулынын" биюләрен өйрәнү. Аяк позицияләре, гәүдәне тоту, тыпырдаулар өйрәнү. Топ бию –"Өчле бию"

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма, аудиоязма.

**7 тема: табигатьнең яз, кыш, җәй, көз бәйрәмнәре һәм йолалары**

Максат: Ел фасылы белән бәйле сынамышларның тормыш көнкүрештә кирәклеге турында төшендерү. Гасырдардан килгән уеннар, туй йолалары, бүген дә әһәмиятле булуын төшендерү. Музыкаль бизәлеш өстендә эшләү, ишетү, сәләтне үстерү. Табигатьтә яз, кыш, җәй, көз айларында үткәрелә торган бәйрәмнәрне киңрәк аңлату.

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма.

**8 тема: инструмент - кораллар**

Максат: Гармун, мандолина, кашыкларда уйнау буенча башкару осталыгын үстерү, мәхәббәт тәрбияләү, аңлату, кирәклеге турында төшендерү. Керәшен халкындагы музыкаль уен кораллары. Музыкаль бизәлеш өстендә эшләү, ишетү, сәләтне үстерү.

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма.

**9 тема: йомгаклау дәресе.**

Максат: түгәрәк эшчәнлегенең еллык эшенә нәтиҗә ясау.

Иҗади эш эшләү. Фикерләр алышу. Алдагы елларга планнар. Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау.

## 5 ЕЛ УКЫТУГА УКУ ПЛАНЫ

| № | Тема | Барлык сәгать | Теория | Практика | **Аттестация формалары** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Юл йөрү буенча кагыйдәләре буенча әңгәмә. | 3 | 3 | - | кереш тест |
| 2 | Татарстан минем | 27 | 12 | 15 | аралашу |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | республикам | | | | |
| 3 | Халкыбызның гореф- -гадәтләре. | 24 | 6 | 18 | аралашу |
| 4 | Керәшеннәрнең көнкүреш тәрбиясе | 24 | 3 | 21 | аралашу, үзлектән эш, иҗади эш |
| 5 | Керәшен халкының авыз-тел иҗаты | 57 | 9 | 48 | үзлектән эш |
| 6 | Табигать бәйрәмнәре һәм йолалары | 72 | 15 | 57 | эшлекле уен |
| 7 | Табигать – безнең йортыбыз | 6 | 3 | 3 | реферат |
| 8 | Йомгаклау | 3 | - | 3 | Йомгаклау чыгышы - шәһәркүләм «Оло Көн» бәйрәмендә катнашу |
| | Барлык сәгать: | 216 | 48 | 168 | |

## 5 ЕЛ УКЫТУГА ПРОГРАММА ЭЧТӘЛЕГЕ

**1 тема: кереш дәрес**

Максат: Балаларны барлау, техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен искә төшерү, уку елы планы, бүлек планына кертелгән кичә, бәйгеләр белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә.

*Күрсәтмә материал* : Обучение школьников правилам безопасного поведения на дороге (1-4 классы): Учебно-методическое пособие / Р.Ш.Ахмадиева, С.А.Бикчентаева, Д.Д.Забиров, Е.Е.Воронина и др./ Под общей ред. Р.Н.Минниханова, Д.М.Мустафина. – Казань: ГБУ «НЦ БЖД», 2013 г.

*Җиһазлау*: компьютер, китаплар.

**2 тема: Татарстан минем республикам**

Максат: үз Ватаныбыз тарихы, мәдәнияте, керәшен горур халкы, аның гореф-гадәт, йолалары белән таныштыру,горурлык хисләре тәрбияләү; Татарстанның күренекле шәхесләре белән танышу, горурлык хисләре тәрбияләү

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар

*Җиһазлау*: компьютер, магнитофон, видеоязма

**3 тема: халкыбызның гореф- -гадәтләре.**

Максат: Халкыбызның гореф – гадәтләре белән таныштыру. “Нардуган” бәйрәменең гореф-гадәтләре. Рус халкынын бәйрәмнәреннә аерымлыгы. Халыкларның тормыш яшәү рәүшендәге үзенчәлекләре һәм аермалыкларын күрә белү һәм аңлау.

*Күрсәтмә материал:* китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: компюьтер, магнитофон, видеоязма.

**4 тема: керәшеннәрнең көнкүреш тәрбиясе**

Максат: Керәшен халкының киемнәренең төрлелегенең әһәмиятен аңлату, мәхәббәт уяту. Хатын-кызлар, ир-егетләр киеменә төшенү. Халыкта һәр бизәкнең оло мәгнәсе булуын аңлату. Керәшен эчемлекләренә, ашларына мәхәббәт тәрбияләү, саулыкка файдасын аңлату. Борынгыдан килгән шифалы эчемлекләр турында аңлату, ашларга мәхәббәт тәрбияләү.

*Күрсәтмә материал* : Тукыма үрнәкләре, күргәзмә оештыру

*Җиһазлау*: компюьтер, китаплар.

**5 тема: керәшен халкының авыз-тел иҗаты**

Максат: Балалар әдәбиятенә мәхәббәт тәрбияләү, балалар фольклоры, язучылары белән танышу. Бәйрәмнәрне белү, саклап калу. Гөреф – гадәтләр уеннарнын саклап калу, мөхәббәт тәрбияләү, йолаларны белү. Сәнгатебезгә мәхәббәт тәрбияләү, җыр сәнгате белән таныштыру. Бию осталыгына өйрәтү, ишетү, сәләтне үстерү

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: компюьтер, магнитофон, видеоязма

**6 тема: табигать бәйрәмнәре һәм йолалары**

Максат: Ел фасылы белән бәйле сынамышларның тормыш көнкүрештә кирәклеге турында төшендерү. Гасырдардан килгән уеннар, туй йолалары, бүген дә әһәмиятле булуын төшендерү. Музыкаль бизәлеш өстендә эшләү, ишетү, сәләтне үстерү. “Раштуа”, “Нардуган”, “Май чабу”, “Берманчек”, “Оло Кон”, “Тручын”, “Ивану”, “Питрау”, “Элжен”, “Пыкрау”, “Микайле”, “Микула “ бәйрәмнәрен тирәнтен аңлату.

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: компюьтер, магнитофон, видеоязма.

**7 тема: табигать – безнең йортыбыз**

Максат: Табигатьне саклау, кеше табигәтьнең бер өлеше икәнлеген аңлату, мөхәббәт тәрбияләү, үз иленңнең, туып үскән җиреңнең кирәклеген аңлату. Халык календары.

Үз күзәтүләреңнән халык календарен төзү , аңлау, өйрәнү.

*Күрсәтмә материал:* презентация, китаплар, фотоальбом.

*Җиһазлау*: компюьтер, магнитофон, видеоязма.

**8 тема: йомгаклау дәресе.**

Максат: биш еллык эшкә нәтиҗә ясау. Йомгаклау чыгышы - Халык иҗаты йортында «Оло Көн» бәйрәмендә катнашу. Йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән чыгарылыш укучыларына "Керәшен фольклоры" өстәмә гомуми белем бирү программасын үзләштерү хакында таныклык бирелү.

## ПРОГРАММАНЫҢ ПЕДАГОГИК-ОЕШТЫРУ ШАРТЛАРЫН ТОРМЫШКА АШЫРУ

**Материаль-техник база:**
1.*Җылы, иркен бүлмә.*
2. *Җиһазлар:*
- укучылар өстәле - 15 шт.;
- укучылар урындыгы – 30 шт.;
- укытучы урындыгы – 1 шт.;
- укытучы өстәле -1 шт.;
- стена тактасы – 1 шт.;
3. *ТСО чаралары*
- ноутбук -1 шт
- колонкалар - 2 шт
4. *Материаллар һәм җиһазлар*:
- тарату материаллары;
-информацион материаллар, карточкалар, дәресләр өчен кирәкле рәсемнәр, методик эшләнмәләр, тестлар, система һәм гомумиләштерүче таблицалар.

**Программаны укыту-методик яктан тәэмин итү**
1.*Методик комплекслар:*
- информацион материаллар, карточкалар, дәресләр өчен кирәкле рәсемнәр, методик эшләнмәләр.
- программаның үтәлешен билгеләү һәм тикшерү өчен: тестлар, система һәм гомумиләштерүче таблицалар.
2. *Дидактик материаллар* (демонстратив һәм тарату) - журналлар, буклетлар, альбомнар, карточкалар, аудиоязмалар.
*“Керәшен фольклоры “ иҗат берләшмәсендә дәресне оештыру түбәндәге таләпләргә җавап бирә:*
- дәреснең максаты белем бирү программасының эчтәлеге белән тәңгәл килә;
- уку материалы дәреснең максаты һәм эчтәлеге нигезендә сайлап алына;
- барлык структур элементларны исәпкә алып вакыт нәтиҗәле кулланыла;
- дәрес формалары: коллектив, инвивидуаль, төркем белән;
- дәреснең темасы һәм эчтәлеге буенча укыту методларының һәм алымнарының туры килүе.

2. *Методлар һәм алымнар.*
Әлеге программаны уңышлы тормышка ашыру өчен укучыларда тотрыклы кызыксыну булдырырга ярдәм итә торган заманча ысуллар кулланыла.
*Эшчәнлекнең төрләре.*
- сүз алымнары: хикәя, әңгәмә, аңлатма, китап белән эшләү һ. б.;
- гамәли ысуллар: сәхнә сөйләме, сәхнәдә үз-үзеңне тоту буенча дәрес, актерлык осталыгына һ. б өйрәтү;
- күрсәтмәле – хәрәкәтле.

*Эмоциональ:* уңыш ситуациясе, бүләкләү һәм шелтәләү, танып-белү, билгеле шәхес булу теләген үстерү.
*Ихтыяри:* укучыларның белем алуга карата җаваплы карашын формалаштыру.
*Социаль:* үзара ярдәмләшү ситуацияләре булдыру, коллектив эш нәтиҗәләре белән кызыксындыру.
*Танып-белү*: укучының субъектив тәҗрибәсенә таяныч, иҗади мөмкинлекләрен хәл итү, проблемалы ситуацияләрне чишү.

Теоретик мәгълүматларны практикада кулллануның төп ысулы дәресләрдә хикәяләү булып тора. Дәрес эчтәлеге, гамәли эшләр укучының теләгенә карап үзгәреп торыла. Укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, дәресләр гадидән катлаулыга таба үткәрелә. Эшчәнлекне алмаштыру өчен сюжетлы уен элементлары һәм динамик паузалар кулланыла, үстерелүче уеннар кертелә.

3. *Уку эшчәнлеген оештыру формалары*: әңгәмә, мөстәкыйль эш, коллектив иҗат эше, укучыларның эшләре буенча фикер алышу, концерт-кичәләрдә, бәйгеләрдә катнашу.

Программа төрле төрдәге бәйге, ярышлар өчен оптималь мөмкинлекләр булдыру, укучыларның иҗади эшләре өчен җирлек тудыруны күздә тота.

Программада каралган укыту-тәрбия бурычларын үтәү өчен дәресләрнең түбәндәгеләре кулланыла:

- сөйләм культурасын үстерү, халык авыз иҗатына карата кызыксыну уяту.
- туган як, милли бәйрәмнәр турында әңгәмәләр.

Шул ук вакытта укучылар мәнфәгате дә исәпкә алына . Укыту бурычларының чишелешенә карап дәресләр түбәндәге төрләргә бүленә:

- яңа белем алу (укытучы теоретик мәгълүматны хәбәр итә). Мондый төрдәге дәрестә укучы яңа тема белән таныша;

. – белем һәм күнекмәләрне формалаштыру дәресләре (педагог җитәкчелегендә мөстәкыйль эшчәнлек);

- кабатлау (материалны үзләштерүнең сыйфатын билгели), мондый дәресләр агымдагы дәресләр булып торалар;
- катнаш дәрес ( берничә укыту бурычын чишү). Теманың үзенчәлегенә карап индивидуаль, төркемләп шөгыльләнергә мөмкин.

Дәрес берничә этаптан тора:

- күрсәтмә-методик рәтне аңлату һәм сәнгать әсәрләре репродукцияләрен демонстрацияләү (әдәби әсәрләрдән өзекләр уку, фильмнар, альбомнар карау укучыларның кабул итүе аша педагогик фикер алышулар оештыра)
- шәҗәрәләр ясау;
- йомгак ясау, фикер алышу.

*Эш алымнары һәм методлары:*

Прграммада укыту формасы буенча эш фронталь, индивидуаль, парлап-парлап, звенолап һәм группалап оештырылырга мөмкин, ләкин ул ничек оештырылса

да, коллектив эчендә шәхесара мөнәсәбәтләр тәрбияләүгә ярдәм итәрлек булырга тиеш.

Фронталь формада укыту материалны бөтен коллективка бирү юлы булса, звенолап һәм төркем белән эшләү юлында укучыларга сәләтләрен ачарга, бер-берсенең ярдәмен тоярга һәр конкрет этапта мөмкинлекләр туа.

Укучыларның укыту һәм тәрбия ихтияҗларын үзенчәлекле итү өчен төркемнәр һәм төркемчекләр белән эшләү тәкъдим ителә (баланың яше һәм берләшмәдә эшләү тәҗрибәсе күздә тотыла). Индивидуаль форма укучының мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнүен искәртә. Монда педагог ярдәме белән баланың эшчәнлеге арта, ул мөстәкыль эшләргә өйрәнә.

Укыту прцессы вакытында түбәндәге дәрес формалары исәпкә алына:

- *типовой дәресләр*(үз эченә теоретик нигез белән танышу һәм теоретик нигезне ныгыту өчен кирәк булган күнегү һәм уеннарны ала);
- иҗади дәресләр (этюдлар, миниатюралар, пантомималар, мезанценалар төзү, презентацияләр, хикәяләр төзү, видео язмалар булдыру һ.б.;
- *практик дәресләр* (экспонатлар, рәсемнәр, модельләр ясау);
- *видеоматериаллар карау;*
- *жырлы – биюле, йола уеннары һәм бәйге программалары*;
- *бәйрәм- йолалар куелышлары.*

**Аттестация формалары/контроль һәм бәяләү материаллары**

*Аттестация / контроль формалары*

